СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**24 сентябрь 2018 ел** **№59**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"2019 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

1)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Яңа Кырлай авылы Татарстан урамы-200 м; Яшел урамы-220м;

Яңа Иябаш авылы Татарстан урамы-600м, Елга арты тыкрыгы, Татарстан урамы-Үзәк урамы, Үзәк урамы-Елга арты урамы ;

Чиканас авылы Совет урамы-460м, Октябрь урамы-350м;

Өчиле авылы Интернат-110м, Тукай урамы-350м;

Иске Юрт авылы Клуб урамы-214м;

Югары Бирәзә авылы Ленин урамы -215м;Пәшкәү-110м;

Күкчә Бирәзә авылы Тынычлык урамы - 292м, Аркылы урамы - 385м.

2) Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Яңа Кырлай авылында Ия елгасы яры буенда агач һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару.

3) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (Яңа Иябаш авылы);

-5 данә (Чиканас, Өчиле, Иске Юрт, Югары Бирәзә, Күкчә-Бирәзә авыллары) мотопомпалар сатып алу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

Әйе                                        юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күплэп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк ур., 3 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Өчиле авылы, Тукай ур., 73 йорт.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы                Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ